**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 18 март № 154

г. Казань

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Алабуга муниципаль районындагы «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе структурасын оптимальләштерү турында

Татарстан Республикасының социаль яклау тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының ««Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Алабуга муниципаль районындагы «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе (алга таба – «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге) структурасындагы 27 койка-урынлы социаль-тернәкләндерү бүлеген ябу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

«Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге әлеге учреждениенең структурасын оптимальләштерү чараларын үткәргәндә хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына 30 көн эчендә «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтенең аерым төрләрен алга таба файдалану турында тәкъдимнәр кертергә (әлеге мөлкәт исемлеге белән);

60 көн эчендә «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге уставына тиешле үзгәрешләрне кертергә һәм аларны дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә;

тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы» ведомствосы буенча социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итүгә чыгымнар өлешендә күздә тотылган акча чикләрендә «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге структурасын оптимальләштерү белән бәйле чараларны үткәрүгә чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алганнан соң 30 көн эчендә элек «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәгенә беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы биргән мөлкәт исемлеге нигезендә башка дәүләт учреждениеләренә бирүне законнарда билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә.

4. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә әлеге карарның 2 нче һәм 3 нче пунктларында күрсәтелгән барлык чаралар тәмамланганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елга Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында» 2016 ел, 18 ноябрь, 849 нчы карарына тиешле үзгәрешләрне кертү хакында хокукый акт проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

5. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына «Доверие» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге структурасын оптимальләштерүгә бәйле чараларны үткәргәннән соң калган акчаны акылы зәгыйфь балалар өчен балалар интернат мәктәпләре педагогик хезмәткәрләренең штат санын Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм балалар оешмалары эшчәнлеге турында һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларны аларга урнаштыру хакында» 2014 ел, 24 май, 481 нче карары таләпләренә туры китерү чараларын финанслауга җибәрергә рөхсәт итәргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\154.docx